ЯКШӘНБЕ
14
ФЕВРАЛЬ
1943 ел.
№ 37 (6759)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

СОҢГЫ СӘГАТЬТӘ

БЕЗНЕҢ ГАСКӘРЛӘР НОВОЧЕРКАССК, ЛИХАЯ, ЗВЕРЕВО, НОВОШАХТИНСК, ЗОЛОЧЕВ ШӘҺӘРЛӘРЕН АЛДЫЛАР

1. 13 нче февральдә безнең гаскәрләр, кискен атака нәтиҗәсендә, НОВОЧЕРКАССК шәһәрен алдылар. Шәһәргә беренче булып генерал-майор иптәш П. Г. ЧАНЧЕВАДЗЕ берләшмәсеннән генерал-майор иптәш А. И. УТВЕНКО һәм полковник иптәш Ф. И. СЕРЕГИН частьтлары бәреп керделәр.

2. Генерал-майор иптәш И. Т. ШЛЕМИН гаскәрләре, һөҗүмне җәелдерүне дәвам итеп, ЛИХАЯ шәһәрен һәм зур тимер юл узелын, ЗВЕРЕВО шәһәрен һәм тимер юл станциясен алдылар.

Шулай ук безнең гаскәрләр НОВОШАХТИНСК шәһәрен алдылар.

3. Украинада безнең гаскәрләр, бик каты сугыш нәтиҗәсендә ЗОЛОЧЕВ шәһәрен һәм тимер юл станциясен алдылар.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

МОСКВА, КРЕМЛЬ.

И. В. СТАЛИНГА

Кадерле Иосиф Виссарионович!

Совет язучылары ватан сугышы фронтларында Кызыл Армиянең гаять зур һөҗүмен һәм тылда совет гражданнарының куәтле хезмәт тырышлыкларын соклану һәм горурлык белән күзәтеп торалар.

Сталинград янында совет армияләренең бөек җиңүенең даны, үзенең бәйсезлеген, намусын, азатлыгын һәм культурасын саклаучы халыкны җиңәргә мөмкин булмауның дәлиле буларак бөтен кешелек дөньясы хәтерендә мәңге сакланыр.

Барлык совет халкын чолгап алган бөек патриотик күтәрелеш белән рухланган СССР халыкларының язучылары һәм СССР Совет язучылары союзы президумының сотрудниклары «Москва», «Матбугат работнигы» һәм «Совет Украинасы өчен» исемле танк колонналары төзелешенә үзләренең средстволарыннан 852.000 сум акча һәм 50.000 сумлык заем облигацияләре керттеләр; шуның өстенә авторлык хокукларын саклау буенча Бөтенсоюз идарәсе «Матбугат работнигы» исемле танклар колоннасына драматургларның авторлык гонорарыннан бүленгән средстволардан 500.000 сум кертте.

Средстволар туплау дәвам итә.

Советлар иленең язучылары, дошманны тар-мар итү буенча бөек эшкә үзләрен һәм көчләрен биргән хәлдә, Сезгә, кадерле Иосиф Виссарионович, озын гомер һәм сәламәтлек телиләр.

СССР Совет язучылары союзы президиумының тапшыруы буенча:

А. ФАДЕЕВ, А. ТОЛСТОЙ, В. СТАВСКИЙ, П. СКОСЫРЕВ. СССР Совет язучылары союзы партия оешмасы бюросы секретаре О. РЕЗНИК. СССР Совет язучылары союзы правлениесенең месткомы председателе В. ФИРСАНОВА.

СССР СОВЕТ ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ПРЕЗИДИУМЫ А. ФАДЕЕВ, А. ТОЛСТОЙ, В. СТАВСКИЙ, П. СКОСЫРЕВ ИПТӘШЛӘРГӘ СССР СОВЕТ ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫНЫҢ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫ БЮРОСЫ СЕКРЕТАРЕ ИПТӘШ О. РЕЗНИККА СССР СОВЕТ ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ПРАВЛЕНИЕСЕНЕҢ МЕСТКОМ ПРЕДСЕДАТЕЛЕ ИПТӘШ В. ФИРСАНОВАГА

«Москва», «Матбугат работнигы» һәм «Совет Украинасы өчен» исемле танклар колонналары төзелешенә 852.000 сум акча һәм 50.000 сумлык дәүләт заемнары облигацияләре керткән СССР халыклары язучыларына һәм Совет язучылары союзы президиумы сотрудникларына, шулай ук «Матбугат работнигы» исемле танклар колоннасы төзелешенә 500.000 сум акча керткән өчен, авторлык хокукларын саклау буенча Бөтенсоюз идарәсенә минем туганлык сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшыруыгызны үтенәм.

И. СТАЛИН.

Январь ае планы 142 процентка үтәлде

Балтач районы «Стахановчы» артеле (председатель иптәш Глаиев) 1942 нче елның производство планын 105 процентка, киң куллану товарлары эшрәп чыгару планын 150 процентка үтәгән иде. Бу курсәткечләре өчен артель ярышта җиңүче итеп билгеләнде һәм ТАССР Совнаркомы тарафыннан 15.000 сум акча белән бүләкләнде.

Артель эшчеләре яңа елда темпларын тагын да көчәйттеләр. Алар январь ае планын 140 процентка үтәргә йөкләмә алганнар иде, аны 142 процент итеп үтәделәр. Тегү цехында иптәш Бәгъдиева бригадасы айлык планны 280 процентка үтәде. Аның бригадасында норманы үтәмәүчеләр юк, барысы да көненә 2—3 норма бирәләр. Иптәш Минһаҗова хәзер эшләп чыгаруны 414 процентка, иптәш Фазлиева 300 процентка җиткерделәр. Мех цехы буенча да январь ае планы арттырып үтәлде. Мех цехы эшчесе иптәш Бәдретдинова айлык планны 242 процентка, Хәсәнова 222 процентка үтәп чыктылар.

Хәзер артель эшчеләре Кызыл Армиянең 25 еллыгын производствода яңа уңышлар белән каршылау өчен көрәшәләр.

Ф. ГАЛИЕВА.

ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ. Эскадрилья командиры гвардия капитаны Алексей Решетов (сулда) гвардия өлкән лейтенанты Николай Сальниковка булып үткән һава сугышы турында сөйли. Сугыш башланганнан бирле иптәш Решетов дошманның 19 самолетын бәреп төшерде. Ул ике тапкыр Кызыл Байрак ордены белән һәм бер тапкыр Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнде. Иптәш Сальников үзе дошманның 4 самолетын, ә группалап сугышканда 8 самолетын бәреп төшерде. Ул да шулай ук өч орден белән бүләкләнде.

ТАСС фотохроникасы.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

13 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

13 нче февральгә каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

Ново-Черкасскидан төньяк - көнчыгыштарак безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Төньяк Донец ярындагы ныгытмалардан бәреп чыгарылган немецлар ике арадагы чикләргә ныгып урнашырга маташканнар иде. Безнең сугышчылар, омтылышлы ударлар ясап, гитлерчыларны аударып ташладылар һәм көнбатышка таба чигендерделәр. Н-че часть дошманга каршы бик каты сугышларда 400 гә якын гитлерчыларны кырды. 8 орудие, 3 миномет, 19 пулемет һәм башка трофейлар кулга төшерелде. Икенче бер участокта немецларның ике рота пехотасы чолгап алынды һәм кырып ташланды. Пленныйлар алынды.

* * *

Красноармейское районында безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар. Н-че часть халык яши торган бер пункт өчен булган сугышта немецларның бер батальонга якын пехотасын юк итте һәм 12 танкысын сафтан чыгарды. Икенче бер участокта безнең сугышчылар гитлерчыларның ныгытылган позицияләрен алдылар. Дошман берничә тапкыр контратакаларга күчеп, карады, ләкин уңышка ирешә алмады. Сугыш кырында дошманның 300 дән артык үле гәүдәләре һәм яндырылган 3 танкысы калды.

* * *

Чугуев районында безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Н-че танк подразделениесе, дошманның оборонасын җимереп, халык яши торган ике зур пунктны алды. Икенче бер участокта немецларның бер часте чолгап алынды һәм ике көнлек сугышлар нәтиҗәсендә кырып ташланды. Сугыш кырында дошманның 800 гә якын үле гәүдәләре калды. Пленныйлар алынды. Трофейлар кулга төшерелде. Шулар арасында 17 орудие, күп пулеметлар, автоматлар һәм винтовкалар бар.

* * *

Курскидан төньяктарак Н-че часть сугышчылары немецлар пехотасының берничә контратакасын кире кайтардылар һәм дошманны зур югалтуларга дучар иттеләр. Икенче бер участокта безнең подразделениеләр гитлерчыларның бер зур отрядын тар-мар иттеләр һәм аларны куып барып, халык яши торган бер пунктны алдылар. Азык һәм кирәк-ярак тутырылган складлар кулга төшерелде.

* * *

Витебск өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды февраль башында немец-фашист басып алучыларның зур җәза отрядына каршы бик каты сугышлар алып барган. Совет патриотлары 200 дән артык гитлерчыны кырып ташлаганнар. Вилейка өлкәсендә хәрәкәт итүче бер отрядның партизаннар группасы дошманның бер тимер юл эшелонын юлдан чыгарган. Бер паровоз һәм 8 вагон җимерелгән. Һәлакәт вакытында 33 гитлерчы үлгән. Бу участокта поездлар йөрүе берничә көнгә туктатылган.

* * *

Күптән түгел немецларның 82 нче пехота дивизиясеннән бер группа офицерлар плен алынды. 82 нче дивизиянең разведка бүлеге начальнигы, плен алынган обер-лейтенант Людвиг Мюлер болай диде: «Сталинград янында һәм фронтның башка участокларында немец гаскәрләренең җиңелүе гаять көчле тәэсир ясады. Хәзер газеталарда фронт линиясен тигезләү һәм кыскарту турында яза башладылар. Ләкин без «фронт линиясен кыскарту» нәрсә икәнлекне беләбез инде. Безнең дивизия чын мәгънәсе белән ике көн эчендә җимерелде. Сугышларның өченче көнендә бөтен дивизиядә бары 1.000 солдат калды. Руслар безнең оборона линиябезне өзделәр һәм шул кадәр тизлек белән алга киттеләр, хәтта без айнырга да өлгерә алмадык. Дивизиянең командиры машинага утырып качты. Һәм мин аны шуннан соң күрмәдем».

* * *

Воронеж өлкәсенең Марки авылында немец-венгер кабахәтләр канлы суеш оештырганнар. Гитлерчылар совет гражданнарын тотып алганнар һәм озак мыскыллаганнан соң аларны үтергәннәр. Гитлерчы ерткычлар бу авылда барлыгы йөздән артык гражданнар халкын газаплап һәм асып үтергәннәр.

13 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

13 нче февральдә безнең гаскәрләр, кискен атака нәтиҗәсендә, Новочеркасск шәһәрен алдылар.

Безнең гаскәрләр, һөҗүмне җәелдерүне дәвам иттереп, **Лихая** шәһәрен һәм зур тимер юл узелын, **Зверево** шәһәрен һәм тимер юл станциясен алдылар.

Шулай ук безнең гаскәрләр **Новошахтинск** шәһәрен алдылар.

Украинада безнең гаскәрләр каты сугыш нәтиҗәсендә **Золочев** шәһәрен һәм тимер юл станциясен, шулай ук район үзәге **Липцыны**, халык яши торган зур пунктлардан Казачьяны, **Лупаньны, Роганьны, Каменнаяны, Яруганы, Тарановканы** алдылар.

Фронтның башка участокларында безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

* * *

12 нче февральдә безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында дошманның гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 300 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 4 артиллерия батареясының утын бастырдылар, бер сугыш припаслары складын һәм бер ягулык складын шартлаттылар, ике батальонга якын дошман пехотасын таркаттылар һәм бер өлешен юк иттеләр.

(Ахыры 4 нче биттә).

Ремонт—чәчүгә әзерлекнең әһәмиятле буыны

Ремонтны шулай үткәрергә кирәк ки, һәрбер трактор сәгать механизмы кебек төгәл эшләрлек булсын!

Яниль МТС ы алдынгылары

КУКМАРА, 13 февраль. **(Телефон буенча).** Данлыклы Кызыл Армиябезнең фронтлардагы уңышлары белән рухланып, Яниль МТС коллективы язгы чәчүгә әзерлектә үрнәк күрсәткечләргә ирешә. МТС ның 36 тракторы язгы чәчүгә әзер инде. Калган тракторларга ремонт төгәлләнеп килә. Шул ук вакытта тагылма инвентарьларга ремонт ясау да кызу темп белән бара: 23 чәчү машинасының 19 ына, 22 культиваторның 18 енә ремонт ясалды инде.

Иптәш Е. Федорова бригадасы 20 нче февральгә 4 тракторны ремонттан чыгарырга йөкләмә алган иде. Бригада 10 нчы февральгә үк 7 тракторга ремонт ясады. Эшнең сыйфаты отлично. Моторларны ремонтлаучы иптәш Филлипова бригадасы да көнлек заданиене 200 процентка кадәр үтәп бара. Бригада 30 моторны ремонтлады инде. Иптәш Хәйретдинов тагылма инвентарьларга ремонт ясый. Ул бер үзе 22 сабанны төзәтте. Насыр иптәш Шакиров бригадасы подшипниклар узелында эшләп, норманы һәрвакыт 250—300 процентка кадәр үти.

МТС ның алдынгы яшь тракторчылары Мостафина, Якупова һәм Хәбибуллина иптәшләр, эштә үзләрен күрсәтүләре өчен, ремонт бригадирлары итеп күтәрелделәр һәм фронтка киткән ирләрне алмаштырдылар. Алар бу яңа эштә дә бик күпләргә үрнәк булып торалар.

МТС та иске частьларга реставрация ясау планы 117 процентка үтәлде. Шулай итеп, бик күп яңа частьларга экономия ясалды. Тракторчылар курсында укучылар МТС ка мең төрлегә якын частьлар җыеп бирделәр. МТС аларның күпчелеген төзәтеп эшкә ярарлык хәлгә китерде. Җыелган частьләр арасында подшипниклар, радиаторлар, һәм башка шундый әһәмиятле детальләр бар.

Тракторчылар арасында политик-масса эшләре яхшы куелган. Агитаторлар Совет Информбюросының белдерүләрен, ватан сугышы фронтларындагы эпизодларны эшчеләргә һәр көн вакытында җиткереп торалар.

МТС ның 12 тракторчысы, 1942 нче елда тракторлардан файдалануда яхшы күрсәткечләр биргәнлекләре өчен, СССР Җир Эшләре Халык Комиссариаты тарафыннан «Социалистик авыл хуҗалыгы отличнигы» значеклары белән бүләкләнделәр. Бүләкләнүчеләр арасында тракторда бары беренче ел гына эшләгән яшь тракторчылардан Гыйззәтуллина, Сафура Мостафина һәм Газизуллина иптәшләр дә бар.

Г. ГАЛИЕВ,
Я. ГАЙНУЛЛИН.

СВОДКА

ТАТАРСТАН АССР МТС ЛАРЫНДА ТРАКТОРЛАРГА РЕМОНТНЫҢ БАРЫШЫ ТУРЫНДА

(ПЛАНГА КАРАТА ПРОЦЕНТЛАРДА)

1943 нче ЕЛНЫҢ 10 нчы ФЕВРАЛЕНА

МТС лар	Үтәлеш	МТС лар	Үтәлеш	МТС лар	Үтәлеш
1. Мөслим	100,0	37. Октябрь	69,0	74. Әхмәт	47,1
2. Чокалы	100,0	38. Олы Кариле	68,0	75. Буденный	45,6
3. Актаныш	100,0	39. Аксубай	67,9	76. Карамалы	45,5
4. Бөгелмә	100,0	40. Әлмәт	66,7	77. Иске Чишмә	45,5
5. Тымытык	97,3	41. Кукмара	66,1	78. Шөгер	45,3
6. Чүпрәле	95,3	42. Кызыл Чапчак	66,1	79. Кичү	45,2
7. Тирсә	95,0	43. Бондюг	64,4	80. Биләр	44,4
8. Ишеево	94,3	44. Б. Матак	62,7	81. Черемуховский	44,4
9. Нөркәй	94,3	45. Тәтеш	62,5	82. Майдан	43,1
10. Саба	92,0	46. Балтач	61,5	83. Питрәч	42,6
11. Алга	90,0	47. Акташ	60,3	84. Кызыл юл	42,2
12. Алабуга	88,6	48. Калинин	60,0	85. Минзәлә	41,3
13. Дөбьяз	87,5	49. Әлши	59,5	86. Чистай	41,2
14. Дәүләки	82,6	50. Беренче Май	58,8	87. Балык бистәсе	40,0
15. Кадряк	81,1	51. Мөслим (Чистай)	58,8	88. Макыл	39,6
16. Мөрәле	80,9	52. Каргалы	58,3	89. Арча	39,5
17. Яниль	79,5	53. Ютазы	58,0	90. Алексеевский	39,1
18. Сарман	77,4	54. Этнә	58,0	91. Иске Писмән	38,3
19. Соколка	76,5	55. Зирекле	57,7	92. Үзәк	38,2
20. Юртыш	75,0	56. Буа	57,4	93. Тат. Ялтан	36,4
21. Димитров	74,3	57. Столбище	57,4	94. Казанбаш	36,4
22. Заинский	74,1	58. Яңа Чишмә	56,9	95. Мамадыш	35,5
23. Азин	73,8	59. Чалпы	56,8	96. Кузнечиха	33,3
24. Норлат	73,8	60. Рождественский	56,2	97. Тат. Ходяш	33,3
25. Зөя	73,8	61. Тельман	55,7	98. Чишмә	33,3
26. Юдино	73,3	62. Куйбышев	54,4	99. Морг	31,4
27. Поповка	73,2	63. Исәнбай	54,1	100. Биектау	31,2
28. Тархан	72,1	64. Солтан	52,9	101. Әлки	30,4
29. Мәлки	72,0	65. Салман	52,6	102. Чиябаш	28,6
30. Чыбыклы	71,1	66. Баулы	51,9	103. Зур Поляна	28,1
31. Чаллы	70,9	67. Теләче	51,0	104. Ключи	27,6
32. Чүрибураш	70,2	68. Кама тамагы	50,0	105. Трехозерский	26,4
33. Иске Тимошкино	70,2	69. Константиновка	50,0	106. Кошкино	21,7
34. Кызыл йолдыз	69,4	70. Ромадан	50,0	Барлыгы:	58,7
35. Т. Тамак	69,2	71. Кәкре елга	49,2	1943 нче елның 5 нче февраленә	53,8
36. Кузайкино	69,1	72. Тәкәнеш	49,1		
		73. Маткауш	48,3		

РЕМОНТ ТӨГӘЛЛӘНӘ

Тәкәнеш районының «Яңалык» колхозында (председателе иптәш Офицеров) язгы чәчүгә әзерлек эше үрнәк булырлык рәвештә оештырылган. Авыл хуҗалыгы инвентарьларын һәм машиналарын ремонтлау төгәлләнеп килә.

Барыннан да элек, колхоз правлениесе бер генә сабанның да һәм тырманың да кырда—кар астында калуына юл куймаган. Алар барысы да колхоз усадьбасында.

Тимерче иптәш Назаров үз эшенә зур игътибар белән карый. Ул 26 ике төрәнле һәм 19 данә бер төрәнле сабанны, 21 тырманы ремонттан чыгарды инде. Хәзер иптәш Назаров чәчү машиналарын ремонтлый.

Сбруйлар әзерләү эше дә яхшы оештырылды. Колхозда 36 сабан камыты, 36 постромка баулары һәм башкалар әзер инде. Бу эштә колхозчылардан Осипов һәм Казаков иптәшләр аеруча яхшы эшлиләр.

М. ХӨСӘЕНОВ.

СОЦИАЛИСТИК ЯРЫШ АЛДЫНГЫЛАРЫ

АПАС, 13 февраль. **(Телефон буенча).** Колхозларда Кызыл Армиябезнең 25 еллыгы хөрмәтенә социалистик ярыш көннән-көн көчлерәк рәвештә җәелә. Бу ярышта күп кенә колхозлар язгы чәчүгә әзерлектә шактый зур уңышларга ирештеләр. «Яңа ил» һәм Энгельс исемендәге колхозларның уңышлары бигрәк тә зур. Алар язгы чәчү өчен кирәкле орлыкларны тулысынча әзерләп куйдылар. Орлыкның сыйфаты яхшы. Кышкы агротехника чараларын үткәрү дә уңышлы бара. Энгельс исемендәге колхоз кар тоту планын 90 процентка, басуга тирес чыгару планын 87 процентка, «Яңа ил» колхозы кар тоту планын 100 процентка, тирес чыгару планын 95 процентка үтәделәр. Авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясау бу колхозларда тәмам булды.

ШӘҺӘР ТРАМВАЕНЫҢ ОТЛИЧНО ЭШЛӘВЕ ӨЧЕН!

(ШӘҺӘР СОВЕТЫНЫҢ XI нче СЕССИЯСЕННӘН)

Казан трамвае турында сөйләгәндә, аны кем генә яхшы сүз белән телгә ала икән!.

Шәһәр трамваеның эше, бигрәк тә кыш кергәннән соң, һич тә гафу ителмәслек дәрәҗәдә начарланып китте. Кайбер маршрутларда трамвайлар хәзер бөтенләй йөрүдән тукталган. Хәрәкәт бар дигән маршрутларда да бик аз санда гына вагоннар йөри, аларны сәгатьләр буе көтәргә туры килә. Трамвайлар еш кына ватылалар, юлдан чыгалар. Гомумән, юлда төрле авария̆ләр бик күп була. Мондый һәрбер авариядән соң хәрәкәт озак вакытка туктала, вагоннар депога борылып кайталар һ.б.

Трамвайның болай хурлыклы рәвештә начар эшләвенең күңелсез нәтиҗәләрен шәһәр хезмәт ияләре һәркөнне үзләренең җилкәләрендә татыйлар. Эшчеләр, хезмәткәрләр заводка, фабрикага, учреждениегә—эш урыннарына—үз вакытында килеп өлгерә алмыйлар, яки дистәләрчә километр җәяү барырга һәм инде арган килеш эшкә керешергә мәҗбүр булалар. Шулай итеп, трамвайның начар эшләве шәһәрнең нормаль тормышын боза, аның барлык халык хуҗалыгына зур зыян китерә, фронт һәм ил өчен продукция җитештерүче промышленность предприятиеләре эшендә җитди тоткарлыклар китереп чыгаруга сәбәпче була.

Казан кебек эре промышленность һәм культура үзәге булган шәһәрдә трамвайны мондый хәлдә калдырырга һич тә ярамый. Аның бүгенге көн таләпләренә тулысынча җавап бирерлек итеп эшләвенә ирешү өчен бик тиз практик чаралар күрергә кирәк. Шул сәбәпле, бу мәсьәләне Казан шәһәр советының чираттагы XI нче сессиясенә махсус рәвештә куеп тикшерү—бик вакытлы һәм актуаль чара.

Хезмәт ияләре депутатларының Казан шәһәр советының 11 нче февральдә үткәрелгән XI нче сессиясендә «Шәһәр трамваеның хәзерге хәле һәм аның эшен яхшырту чаралары турында» докладны шәһәр Советы Башкарма Комитеты председателе иптәш Тышкевич ясады.

— Шәһәр трамвае үз алдына куелган зур һәм җитди бурычларны бүгенге көндә һич тә үтәми,—ди иптәш Тышкевич.— Трамвайның хәрәкәт составы һәм юл хуҗалыгы бик начар хәлдә. Вагоннарның бик аз өлеше генә йөри, калганнары күп вакытларны ремонтта үткәрәләр. Аварияләр саны һаман арта бара. Техник күзәтчелек начар сештырылган. Техник эксплоатация кагыйдәләре үтәлми. Трамвай хуҗалыгы тиешле кадрлар белән, кирәкле материаллар белән һәм ныклы техника база белән тиешенчә тәэмин ителмәгән. Хезмәт дисциплинасы бик түбән. Шушындый авыр хәлнең нәтиҗәләре кайбер цифрларда аеруча ачык чагыла. Узган елны, мәсәлән, трамвайда пассажирлар йөртү планы нибары 41,4 процентка гына үтәлгән. Шәһәр бюджетына трамвай 4 миллион сумнан артык доходны биреп җиткермәгән.

Болар барысы да—шәһәр трамваеның элекке җитәкчелеге (директоры Громов, баш инженеры Миронов) тарафыннан күрсәтелгән булдыксызлык, инициативасызлык нәтиҗәсе, аларның җинаятьчел рәвештә начар эшләүләре нәтиҗәсе булып тора. Шәһәр советы башкарма комитетының гаебе—трамвайның эше белән системалы һәм җитди рәвештә шөгыльләнмәүдә, эшлексез, булдыксыз җитәкчеләргә карата йомшаклык күрсәтүдә һәм аларны озак вакыт үз постларында калдырып килүдә.

Шәһәр трамваеның яңа җитәкчелеге (директоры Егоров, баш инженеры Юдин) алдында хәзер, кичекмәстән һәм үрнәк төстә үтәлергә тиеш булган, гаять зур, җитди бурычлар тора. Шәһәр трамвае һичшиксез отлично эшләргә тиеш. Трампаркларның хәрәкәт составы 100 проценты белән хәрәкәттә булырга, хәрәкәт һәм ремонт планнары, графиклар төгәл үтәлергә, трамвайның барлык тармакларында да хезмәт дисциплинасы җитди рәвештә ныгытылырга тиеш. Шәһәр һәм район советларының, промышленность предприятиеләренең трамвайга эшлекле ярдәм күрсәтүләрен нык кына көчәйтергә һәм бу ярдәмне системага кертергә кирәк. Бу—трамвайның эшен яхшыртуда төп чараларның берсе итеп каралырга тиеш. Аеруча алганда, трамвайның эше белән турыдан-туры кызыксынган предприятиеләрнең аңа практик ярдәм күрсәтүләренең никадәр яхшы нәтиҗә бирүен аерым мисалларда бик ачык бирергә мөмкин. Баш инженеры Корнеев, партоешма секретаре урынбасары Ставер иптәшләр булган заводлар һәм төзү тресты трамвай эше белән практик рәвештә шөгыльләнә һәм аңа кирәкле ярдәмне оештыра башлагач та, моңа кадәр бик начар эшләүче маршрутларның берсе хәзер үз эшен сизелерлек рәвештә яхшырта бара. Бу файдалы практиканы шәһәр күләмендә киң кулланырга кирәк.

Доклад буенча фикер алышуларда Киров райсоветы председателе Скрипкин, төзү тресты директоры Ястребилов, 4 нче номерлы ясалма каучук заводы директоры Карташев, шәһәр трамвае директоры Егаров, стахановчы кондуктор Агафонова, ВКП(б) ның Ленин райкомы секретаре Гриньков, РСФСР коммуналь хуҗалыгы халык комиссары Макаров, Н-че завод директоры һ. б. иптәшләр чыгып сөйләделәр. Алар трамвай эшендәге җитди кимчелекләрне каты тәнкыйть уты астына алу белән бергә, анда эшне яхшырту өчен нинди практик чаралар үткәрергә кирәклеген дә күрсәттеләр.

Сессия шәһәр трамваеның якын араларда үрнәк төстә эшләүгә ирешүенә юнәлдерелгән конкрет карар кабул итте. Шәһәр трамвае коллективының, шәһәр һәм район советларының һәм аларның барлык депутатларының, трамвай хезмәт күрсәтә торган барлык предприятие җитәкчеләренең бурычлары—сессиянең бу карарын тулысынча һәм билгеләнгән срокларда үтәүдән, шәһәребездә трамвайларның төгәл хәрәкәтен булдыруга һәм шуның белән шәһәрнең, предприятиеләрнең нормаль тормышларын, эшләрен тәэмин итүгә ирешүдән гыйбарәт булырга тиеш.

Сессия шулай ук кайбер оештыру мәсьәләләрен дә карады. Башка эшләргә күчерелгән иптәшләр урынына, шәһәр советы председателенең урынбасарлары итеп Александров, Мулюков, Безбородов, Зинанов, шәһәр план комиссиясе председателе итеп Маркович, шәһәр сәламәтлек саклау бүлеге мөдире итеп Потехин, коммуналь хуҗалык бүлеге мөдире итеп Кукушкин, мәгариф бүлеге мөдире итеп Куницина, сәүдә бүлеге мөдире итеп Васютин, сәламәтлекне саклау буенча даими комиссия председателе итеп Тихонов, оборона-физкультура эшләре буенча даими комиссия председателе итеп Сафонов иптәшләрне билгеләү турындагы карарлар расланды. Шәһәрдән киткән Бычков, Соколов, Тарасов, Гобәйдуллина иптәшләр Казан шәһәр советы депутатлары хезмәтләреннән азат ителделәр.

Түбәнге палатада Черчилльнең чыгышы

ЛОНДОН, 12 февраль. (ТАСС). Англия информация министрлыгының белдерүенә караганда, баш министр Черчилль түбәнге палатада хәрби хәл турында речь белән чыккан.

Касабланкада булган конференциядә безнең үз алдыбызга куйган төп максатыбыз,—дигән ул,—дошманның көчләренә каршы коры җирдә дә, диңгездә дә һәм һавада да мөмкин кадәр киңрәк масштабларда һәм мөмкин кадәр тизрәк сугышу. Дошман белән якынрак килеп сугышуның һәм көрәшне көчәйтүнең кирәклеге, гадәттә, үзеннән-үзе хәлкылгыч булуы мөмкин булган башка төрле фикерләрдән өстен тора. Безгә дошманны рус фронтының бөтен киңлекләрендә—Ак диңгездән Кара диңгезгә кадәр—кырган һәм хәлсезләндергән кебек үк бөтен физик мөмкинлекләр һәм акыллы алымнар белән кырырга һәм хәлсезләндерергә кирәк.

Бу бурычны хәл кылганда, Бөек Британия һәм АКШ зур кыенлыкларны җиңәргә тиешләр, дип күрсәтеп, Черчилль су асты сугышы турындагы мәсьәләгә җентекләп тукталган.

Англия һәм Америка хөкүмәтләре үзләренең барлык планнарында су асты сугышы куркынычын җиңүне беренче урынга куйдылар. Бу күрсәтмә Касабланкада берләшкән штабларның вәкилләре тарафыннан бик ачык рәвештә расланды. Без, — дигән Черчилль, — диңгездә зур югалтуларга дучар булабыз, алар безгә комачаулыйлар һәм безнең операцияләребезне тоткарлыйлар. Ләкин су асты көймәләренә каршы көрәш шулай да уңышлы бара. Бу көрәштә без өстен һәм хәтта күбрәк өстен чыктык.

Соңгы 6 ай эчендә яңа судноолар төзү, шул исәптән Американың һәм Канаданың эре судноолар төзелеше, берләшкән милләтләрнең барлык югалтуларына караганда, 1.250 мең тоннадан артып китте, ә соңгы ике айда булган югалтулар бер елдан артык вакыт эчендәгегә карата да азрак булдылар. Германиянең су асты көймәләренең саны арта бара, ләкин шулай ук аларның югалтулары да арта, һәм аларга каршы һөҗүм итү алымнары да, шулай ук алардан карваннарны саклау методлары да яхшыра баралар. Ләкин, дип дәвам иткән Черчилль, без мондый масштабтагы югалтуларга, гәрчә алар яңа төзелеш исәбенә капланып барсалар да, киләчәктә юл куя алмыйбыз.

Әгәр дә Англия һәм АКШ, су асты көймәләренә каршы көрәштә үзләренең тырышлыкларын һәм көрәшләрен йомшартмасалар, безнең планнарыбызда һәм хәрәкәтләребездә үзләренең өстенлекләрен сакласалар, дигән Черчилль, мин пароходчылык мәсьәләсендә 1943 нче елның ахырына хәзергегә караганда яхшырак хәлдә булачагыбызга түбәнге палатаны ышандыруны үз өстемә алам, ә мин әлегә кадәр аны ялгыш фикергә китергәнем юк. Гәрчә алга, еракка карарга омтылу саксызлык булса да, бу яхшы өйрәнелгән өлкәдә бөтенләй яңа һәм көтелмәгән нинди дә булса хәл килеп чыкмаса, барлык тенденцияләр шуны раслыйлар ки, ул вакытта 1944 нче елның ахырына, әгәр дә әйтик, сугыш шул вакытка кадәр сузылса, без тагын да яхшырак хәлдә булырбыз.

Без пароходларны никадәр азрак югалтсак, Англия-Американың хәрби тырышлыклары шул кадәр интенсиврак булуы мөмкин. Тоннажны арттыру дошманга тагын да авыррак ударлар ясарга мөмкинлек бирәчәк. Россия өстеннән без ала алырлык авырлыкның күләме дә, шулай ук сугышның никадәр тиз бетерелүе дә яңа судноолар төзелеше күләменең югалтулардан никадәр өстен булуына бәйләнгән.

Дошман, әгәр дә аңа бу кирәк икән, су асты сугышы алып бару юлы белән үзен һәлакәттән коткару турындагы өметләре белән хыяллана бирсен. Ул бу һәлакәттән котыла алмаячак, ләкин аны кичектерә алачак, һәм безнең бурыч, барлык мөмкин булган тырышлыкларны көчәйтеп, бу кичектерү вакытын кыскартудан гыйбарәт. Безнең тормышыбызны, азатлыгыбызны саклап калуга бәйле булган барлык моментлар салкын канлылык һәм аеклык белән исәпкә алынганнан соң, президент, хәрби кабинетның вәкиле буларак минем тулы ризалыгым белән, Касабланкадагы конференциянең төп принципы, безнең барлык дошманнарыбызның тулысынча һәм һичбер сүзсез капитуляция ясауларын таләп итүдән гыйбарәт, дигән карарга килде. Дошманның һичсүзсез капитуляция ясавын безнең кискенлек белән таләп итүебез, ул аның барлык халкы белән гаделсез рәвештә һәм каты эш итеп үзебезнең җиңүле коралыбызга тап төшерәбез дигән сүз түгел, ләкин җинаятьчеләр хаклык суды кулына тотып бирелергә тиешләр, бу суд каты һәм рәхимсез булырга тиеш. Эш эшләнеп беткәннән соң, ә ул, һичшиксез, эшләнәчәк, нацистик һәм фашистик көчнең һәм япон сугыш машинасының без бернинди эзен дә калдырмаска тиешбез.

Хәзер безнең коралы көчләребезнең бурычларын, шулай ук аларның хәрәкәт юнәлешләрен билгеле торган, бөтен нәрсәне эченә ала торган хәрәкәт планыбыз бар, һәм без бу планны безнең политикабызга туры китереп якындагы 9 ай эчендә тормышка ашырырга уйлыйбыз, бу вакыт үткәнче без, һичшиксез, яңадан очрашырга тырышырбыз.

Англиянең һәм Американың экспертлары һәм политик җитәкчеләре бер үк телдә иркен рәвештә һәм ачыктан-ачык фикерләрен аңлаша алганлыктан гаять зур өстенлек белән файдаландылар. Ләкин бу хәл, Сталинның һәм аның күренекле генералларыннан кайберләренең безнең арабызда була алмауларына карата безнең тирәнтен тәэссеф белдерүебезне аз гына да киметми. Президент Рузвельт, үзенең физик сәламәтсезлегенә дә карамастан,—бу хәлен ул героик дәрәҗәдә җиңеп килде,—һәр өч якның очрашуына өметләнеп, Хартумга кадәр барырга да әзер иде. Ләкин баш министр Сталин русларның барлык гаять зур һөҗүменең верховный җитәкчесе булып тора, бу һөҗүм ул вакытта тулысынча җәелдерелгән иде, һәм ул тайпылышсыз рәвештә триумфаль төстә җәелүендә дәвам итә.

Ул безгә белдергәнчә, ул үзенең постын бер генә көнгә булса да калдырып китә алмады, ләкин мин палатаны ышандыра алам, аның булмавына да карамастан, без үз алдыбызга беренче бурыч итеп русларның гаять зур һәм гүзәл тырышлыкларына булышу өчен, дошманны һәм аның һава көчләрен рус фронтыннан тартырга омтылу өчен безнең кулыбызда булган нәрсәләр белән максимум ярдәм итүне куйдык, чөнки су асты сугышы мәсьәләләре шундый итеп куелдылар ки, алар безгә һөҗүмчән хәрәкәт итәргә мөмкинлек бирәләр.

Англиянең һәм Американың стратеглары һәм лидерлары Гитлерның җиңелүе һәм Германиянең куәтен тар-мар итү, Япония белән булган сугышның хәлиткеч фазасына караганда да беренче урын алырга тиеш, дип моннан бер ел элек кабул ителгән карарга бердәм рәвештә кушылалар. Мин моннан ике ай элек, Европада дошманны тар-мар итүгә Японияне җиңгәнчегә кадәр ирешелүе мөмкин дип белдергән идем, һәм мин мондый хәлдә Британия империясенең барлык көчләре—коры җир, диңгез һәм һава көчләре—мөмкин булган кадәр тизлек белән Ерак Көнчыгыш театрына күчереләчәкләр һәм Англия, АКШ белән берлектә, сугышны Японияне һичшиксез капитуляция ясарга мәҗбүр булуына кадәр көчле энергия белән дәвам итәчәк, дип белдердем.

Хәзерге вакытта Японияга каршы сугышта Англиянең хәрәкәтләре, операцияләрнең Һиндстан театры белән чикләнәләр. Безнең Азиядәге хәрби тырышлыкларыбыз, аерым алганда, Кытайга мөмкин булган һәртөрле ярдәм күрсәтү өчен Бирма юлын ачуга юнәлдерелгәннәр. Без генералиссимус Чан Кай-ши белән якын элемтәдә торабыз. әгәр дә ул килә алган булса аны конференциядә күрү белән без шатланган булыр идек. АКШ ның хәрби һава көчләре командующие генерал Арнольд һәм фельдмаршал Дилл хәзер Чунцинда һәм алар без күздә тоткан нәрсәләрне генералиссимус белән тикшерәләр. Кытайның озакка сузылган һәм тайпылышсыз көрәшенең хәзерге этабында без яңа биргән зур өстәмә ярдәм уңае белән генералиссимусның канәгатьләнү белдергәнлеге турындагы хәбәрне алдык инде. Киләчәктә Ерак Көнчыгышта булачак хәрәкәтләр турында, безнең сөйләшүләребезнең нәтиҗәсе сыйфатында без хәбәр иткән планнар белән дә генералиссимус килешә.

Касабланкада кабул ителгән карарлар һәм аларның нәтиҗәләре турында игълан ителергә мөмкин булганнарыннан менә шуларны әйтергә мөмкин.

Ләкин мин шуны өстәргә тиешмен: Россия эшләгәннәрнең барысына, Совет армиясенең гаять зур уңышларына карап, әгәр дә, Англиянең һәм Американың короллы көчләрен соң дәрәҗәдәге тизлек һәм энергия белән, иң киң масштабларда дошманга каршы хәрәкәткә китерү өчен кеше көче җитә ала торганнарның бөтенесе дә эшләнүгә һәм эшләнәчәккә бөтен йөрәгем һәм аңым белән ышанмасам, мин үземне вакыйгалар таләп иткән югарылыкта түгел дип хис итәр идем. Президент һәм мин бу турыда безнең хәрби киңәшчеләребезгә һәм экспертларыбызга ныклык белән һәм аеруча әйтеп күрсәттек. Аларның планнарын һәм көчләрне урнаштыруларын яхшы дип тапкан хәлдә, без атакаларга зур көч бирергә һәм аларны зур тизлек белән үткәрергә рәсми рәвештә тәкъдим иттек. Бу максатка ирешү өчен Атлантиканың һәр ике ягында энергияле тырышлыклар куела.

Черчилль болай дигән: Рузвельтның тулысынча ризалыгы белән мин Төркия җитәкчеләре белән киңәшмәгә бардым. Бу киңәшмә уңае белән инде игълан ителгән белдерүнең юллары арасыннан укуга каршы мин кисәтү ясадым инде. Безнең политикабыз бернечек тә Төркияне кыен хәлгә куюга юнәлдерелмәгән. Киресенчә, Төркиянең һәлакәте Англиянең һәм барлык берләшкән милләтләрнең һәлакәте булыр иде. Төркия әлегә кадәр нинди дә булса яктан агрессиягә каршы ныклы киртә тотып килде, һәм шуның нәтиҗәсендә хәтта иң кара көннәрдә дә, ул сугышның Төркия аша Иранга һәм Гыйракка таралуын булдырмыйча, көнчыгыштагы барлык сугышлар өчен тормыш ягыннан әһәмияте булган Абадан нефть промыслоларына куркынычны бетереп, безгә бәя биреп бетермәслек хезмәт күрсәтте.

Берләшкән милләтләр, аеруча Англия Төркиянең хәзерге заман сугышы кораллары белән яхшы коралланган булуы һәм аның батыр пехотасының хәзерге заман сугышы кырларында хәлиткеч роль уйный торган мөһим коралларда җитешмәүчелек күрмәве белән бик нык кызыксыналар. Хәзер, беренче тапкыр буларак, без һәм Кушма Штатлар бу корал белән Төркияне, аның тимер юлларының һәм башка коммуникацияләренең үткәрү сәләте мөмкинлек биргән дәрәҗәдә тәэмин итү мөмкинлегенә ия булып торабыз. Без аңа ул никадәр ала алса, шул кадәр бирә алабыз, һәм без бу коралны Төркия гаскәрләре аны ни дәрәҗәдә үзләштерүгә караганда да тизрәк илтеп бирә алабыз. Безнең киңәшмәбездә мин, бу яңадан коралланууны җентекләп оештырудан башка нинди дә булса башка таләпләр куймадым. Хәзерге вакытта Әнкарәдә Англия Төркиянең катнаш хәрби миссиясенең утырышлары бара. Ул, Төркия армиясе эффектлылыкның максималь дәрәҗәсенә җитсен өчен, шушы яңа коралларны кертү һәм коммуникацияләрне яхшырту юлы белән Төркиянең гомуми оборона куәтен максималь дәрәҗәдә үстерү мәсьәләләре белән шөгыльләнә. Төркия безнең союзникыбыз һәм дусыбыз. Һәм без, аның территориясе, аның интереслары һәм хокуклары эффектлы итеп саклануын тели алабыз. Без 20 еллык Англия-Рус договоры белән бәйләнгән безнең бөек төньяк дустыбыз һәм Төркия арасында якын һәм дусларча мөнәсәбәтләр урнашуны аеруча телибез.

Аннары Черчилль үзенең Кипрда, Каһирәдә, Триполида булуына тукталган. Ул, Эль-Аламейн янында Роммель гаскәрләренең тар-мар ителү шартларын искә төшергән.

Төньяк Африкадагы операция турында, дигән Черчилль, узган елның август аенда бу турыда мин Сталинга сөйләгәч, ул әйткән сүзләр белән фикер йөртергә мөмкин, дип исәплим. Ул, бу операция хәрби яктан дөрес булып тора дип белдерде. Бу операция, һичшиксез, сугышның стратегик күчәрен үзгәртте. Төньяк-Көнбатыш Африкага уңышлы рәвештә 500 меңгә якын кеше төшерелде, һәм хәзер, бу гаскәрләр Кушма Штатлар контролендә торалар.

Кайбер кешеләр Франциянең төрле рәсми кешеләренең узгандагы хәрәкәтләре турындагы мәсьәлә белән мәшгульләр, американлылар фикеренчә, аларны эштә файдалану яхшы булачак. Миңа килгәндә, мин икърар итәргә тиешмен, мин армиянең куркынычсызлыгы һәм операцияләрнең уңышлылыгы белән барыннан да күбрәк дәрәҗәдә кызыксынам, алар тиз арада үзләренең югары ноктарына җитәчәкләр.

Үзенең речен тәмам итеп, Черчилль болай дигән: Мин, үземнең ышануымча, дошманга билгеле булган барлык нәрсәләрне палатага сөйләргә һәм дошман белмәскә тиеш булганнарны әйтмәскә тырыштым. Һәр хәлдә, мин Атлантиканың һәр ике ягындагы барлык патриотларга мөрәҗәгать итәм: Ризасызлык һәм ызгыш чыгаручы һәрбер кешене, алар кайда гына булсалар да, каты рәвештә җәзалагыз, безнең сугыш машиналарыбызның, безнең эшебез өчен мөмкин булган аеруча уңайлы шартларда сугышка керүләрен тәэмин итегез.

Киң куллану товарларын үзебез җитештерәбез

ССР Союзы Наркомторгының Казандагы универмагы коллективы 1942 нче елда халыкны киң куллану товарлары белән тәэмин итүдә зур тырышлык күрсәтте.

Сугыш вакытының кыенлыкларына карамастан, без беренче чиратта кирәкле әйберләрне җитештерү өчен, магазин янында промкомбинат оештыруга ирештек. Комбинатка ватан сугышы инвалиды иптәш Степанов җитәкчелек итә. Ул үзенә тапшырылган эшне беренче көннәрдән үк уңышлы башкара башлады.

Промкомбинат үзенең эшен, башлыча, җирле промышленностьтан, Мехкомбинаттан, тегү фабрикаларыннан һәм башка предприятиеләрдән калган отходлар базасында оештырды.

Комбинатның якты бинасында көне буе кызу эш кайный. Анда, башлыча, яшь үсмерләр эшлиләр. Тәҗрибәле мастерлар җитәкчелегендә алар тегүчелек, итекчелек, скорняклык эшенә өйрәнәләр. Хәзер алар хатын-кызлар, ирләр, балалар өчен өске киемнәр тегәләр, мех изделиеләрдән яка, колакчын бүрек, кыска тун, мех оек тегәләр, балалар уенчыклары ясыйлар.

Яшь кадрлар әзерләүдә итек цехы мастеры Иван Иванович Ржанин гүзәл үрнәкләр күрсәтә. Кыска гына вакыт эчендә ул итекчелек эшенә 30 га якын яшь үсмерне өйрәтте. Аннан өйрәнеп чыккан яшьләрдән Борис Дубов, Петр Андрюшин, Юрий Бабушкин, Иван Быков һәм башкалар хәзер үзлекләреннән эшлиләр һәм көнлек нормаларын 115—130 процентка үтәп баралар.

Кызлардан Гасимова, Хөснуллина, Хәкимовалар квалификацияле әзерләүчеләр булып җитештеләр. Бу яшь патриотлар производствода фронтка киткән квалификацияле эшчеләрне алмаштырдылар һәм үзләренең хезмәтләре белән Кызыл Армиягә ярдәм итәләр. Биредә һәртөрле һөнәрләргә барлыгы 130 яшь үсмер өйрәтелде.

Промкомбинат узган елның IV нче кварталдагы производство планын 114,3 процентка үтәде. Хезмәт җитештерүчәнлеге биредә 16 процентка күтәрелде. Аяк киемнәре цехы буенча бер изделиене эшләүгә китә торган материалга экономия 15,6 процентка җитте.

Хезмәт ияләренә сату өчен китә торган төрле товарлар эшләп чыгаруны арттыруда промкомбинат зур роль уйнады. Промкомбинаттан тыш, магазинның күп кенә промартельләр белән договоры бар. Бу артельләр республика эчендә үзебез эзләп тапкан чималдан безнең заказларны үтиләр. Кышкы изделиеләр ассортименты планын магазин 348 процентка үтәде.

Сәүдә һәм җәмәгать туклануы работникларының Бөтенсоюз социалистик ярышына кушылып, Союзунивермаг коллективы халыкка киң куллану товарларын мөмкин кадәр күбрәк бирергә йөкләмә алган иде. Коллектив үзенең йөкләмәсен уңышлы үтәп чыкты. IV нче кварталда планнан тыш 29 процент күләмендә төрле товралар сатылды. Үзәкләштерелмәгән әйберләр сату планы 233 процентка үтәлде. Әзер киемнәр секциясе (мөдире иптәш Гайнетдинов) 133 проценттан артык товар урнаштырды. Культтоварлар секциясе планнан тыш 19,3 процент товар сатты.

Тагын шунысы характерлы, бу ел универмагта урлау һәм югалту фактлары бөтенләй бетерелде.

Союзунивермаг коллективында 40 лап стахановчы һәм ударник санала. Алар арасында прилавка работникларыннан Бахвалова, Нәҗметдинова, Улыбин һәм башкалар бар.

Кызыл Армиянең 25 еллыгы хөрмәтенә социалистик ярышка кушылып, магазин коллективы яңа йөкләмәләр алган иде: товар әйләнеше буенча квартал планын 10 көнгә элек үтәргә, I нче кварталда үз производствобызда продукция эшләп чыгаруны 20 процентка арттырырга, эшләп чыгарылган продукциянең үзенә төшү бәясен планга караганда 2,5 процентка киметергә, производстводагы эшчеләрнең хезмәт җитештерүчәнлеген 5 процентка күтәрергә һ. б.

Без бу йөкләмәләрне дә уңышлы үтәп киләбез.

Н. КӘРИМОВ,
Казан универмагы директоры.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

13 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

(Ахыры. Башы 1 нче биттә).

* * *

Шахты районында безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүмне җәелдерделәр. Немецлар шәһәрдән чигенгәннән соң башка урында оборона оештырырга маташып карадылар. Безнең частьлар дошман пехотасының каршылык күрсәтүен бастырдылар һәм халык яши торган зур пунктларны алдылар. Бик күп трофейлар кулга төшерелде. Аларның саны алына. Безнең зенитчиклар немецларның 4 самолетын атып төшерделәр.

* * *

Ворошиловск районында безнең частьлар, дошманның каршылык күрсәтүен җиңеп, алга киттеләр. Тулы булмаган саннарга караганда, 1.200 дән артык немец солдатлары һәм офицерлары юк ителде. 5 танк, 2 бронемашина, 19 орудие, танкка каршы ата торган 5 мылтык, 70 автомашина, 80 повозка, җигү кирәк-яраклары белән 200 ат, 7 паровоз, завод җиһазлары төялгән 2 тимер юл составы һәм башка трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Красноармейское янында безнең гаскәрләр дошманның каты каршылык күрсәтүче частьларына каршы бик каты сугышлар алып бардылар. Немецларның пехотасы һәм танклары, югалткан позицияләрен кайтарырга маташып, берничә тапкыр контратакалар ясадылар. Гитлерчыларның барлык контратакалары алар өчен зур югалтулар белән кире кайтарылдылар. Н-че часть сугышчылары бер тимер юл станциясе өчен булган сугышларда немецларның 15 танкысын, 6 бронемашинасын юк иттеләр. 8 паровоз һәм 2 бронемашина кулга төшерделәр. Икенче бер участокта дошманның 500 гә якын кешедән торган отряды, 14 танк, ярдәме белән, Н-че подразделениегә каршы атака ясады. Безнең артиллеристлар һәм бронебойщиклар, ачык позицияләрдән атып, дошманның 5 танкысын яндырдылар һәм зарарладылар. 300 гә якын гитлерчылар кырып ташланды. Дошман тагын берничә тапкыр уңышсыз контратакалар ясап карады, ләкин, сугыш кырында күп үле гәүдәләрен, шулай ук зарарланган 6 танкысын калдырып, тәртипсез рәвештә чигенде.

* * *

Лозовая станциясендә безнең частьлар, беренче алынган саннар буенча, инженерлык милекләре складлары, бер сугыш припаслары склады, бер азык склады, он һәм ашлык склады, 9 паровоз, 120 автомашина, 300 мотоцикл һәм башка трофейлар кулга төшерделәр. Трофейларның саны алына.

Чугуев районында безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Немецларның 320 нче пехота дивизиясе тар-мар ителде. Соңгы ике көн эчендә генә дә бу дивизиянең частьларыннан 3.500 солдат һәм офицерлар үтерелде. 20 орудие, 200 автомашина һәм йөк төялгән 500 гә якын олау кулга төшерелде.

* * *

Могилев өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче отрядның партизаннары немецларның гарнизонарына берничә һөҗүм ясаганнар. 150 гитлерчы кырып ташланган. Бу отрядның партизаннары январь аенда дошманның 7 тимер юл эшелонын юлдан чыгарганнар.

Полесье өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды январь аенда дошманның 11 эшелонын юлдан чыгарган.

* * *

Волхов фронтында немецларның 227 нче Гренадер дивизиясеннән бик күп солдатлар плен алынды. Бу дивизиянең 366 нчы полкыннан плен алынган солдатлардан Иоганн Гоннер, Берингард Дикман, ефрейтор Эрнстфиц, обер-ефрейтор Вилли Бранд һәм башкалар болай диделәр: «Русларның артиллерия уты безнең күп подразделениеләрне ялангач калдырды. Батальонның командирлары, позицияләрне ничек кенә итеп булса да тотып калу турында радио буенча бер-бер артлы приказлар биреп тордылар. Ләкин русларның танклары безнең оборона линиясен өзделәр. Алар артыннан пехота килде. Руслар безнең траншейларга бәреп кердeләр һәм анда булган немец солдатлары барысы да, алдан сүз куешмыйча, команда бирелгән кебек, кулларын күтәрделәр».

* * *

Ростов өлкәсе, Старая Станица хуторында гитлерчы кабахәтләр 18 пленный кызылармеецны, колхозчы Просковья Шенкареваны һәм аның ике баласын тере килеш яндырганнар. Кызыл Армия частьлары килергә бер көн калганда немецлар хуторга ут төрткәннәр. 147 колхозчының йорты, мәктәп, клуб, амбарлар һәм барлык башка хуҗалык каралтылары янып беткән.

ТӨНЬЯК АФРИКАДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

ЛОНДОН, 12 февраль. (ТАСС). Франциянең Төньяк Африкадагы көчләре штабының белдерүендә әйтелүенчә, һаваның начар булуы коры җир операцияләренә тоткарлык ясаган.

Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Англиянең Якын Көнчыгыштагы кораллы көчләренең баш командующие генерал Александер Каһирәдәге хәрби хәбәрчеләргә дошманның Триполитаниядән бөтенләй куып чыгарылганлыгын белдергән. Англиянең 8 нче армиясе патрульләре Тунис территориясенә шактый эчкәрегә үтеп кергәннәр. Роммель Германиянең Тунистагы гаскәрләренең күчәр державаларының Тунистагы гаскәрләре белән кушылырга бара. Ул, аерылып калу куркынычы туганчыга кадәр, Марет линиясендә мөмкин кадәр озаграк калырга тырышачак. Марет линиясе астында, Габес каршында, бик яхшы позиция бар, чөнки анда таулыклы урын, ләкин бу позиция Марет линиясе кебек ныгытып хәзерләнмәгән. Марет линиясе 40 миль озынлыкта гына, ул бик үк уңайлы позиция түгел, һәм аны фланглардан хәрәкәттәге частьлар белән әйләнеп үтәргә мөмкин. Көчле яңгырлар союзникларның хәрәкәтләренә комачаулыйлар.

ТУНИСТА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

ЛОНДОН, 12 февраль. (ТАСС). Рейтер агентлыгының Тунистагы Матәр секторында Англиянең беренче армиясендәге махсус хәбәрчесенең язуына караганда, союзникларның җирле полктан һәм Англия—Франция отрядларыннан торган гаскәрләре Тунис фронтының төньяк секторында итальяннарның позицияләренә атака ясаганнар. Хәбәрченең әйтүенчә, атака 10 нчы февральдә караңгы төшәрәк башланган, ә кич белән союзниклар отрядлары үзләре билгеләнгән беренче урыннарга барып җиткәннәр.

Әлегә кадәр алынган хәбәрләргә караганда, операция союзниклар өчен уңайлы бара, ләкин әле операцияләрнең икенче өлеше тәгалләнми торып соңгы нәтиҗәләрне белергә мөмкин түгел. Союзниклар гаскәләре көнчыгышка таба 8 миль чамасы алга киткәннәр.

ЮГОСЛАВИЯДӘ ПАРТИЗАННАР КӨРӘШЕ

ЖЕНЕВА, 12 февраль. ТАСС). Югославиядән алынган хәбәрләргә караганда, партизаннар азат ителгән территориягә каршы һөҗүм итеп килүче немец-фашист гаскәрләр белән бик каты сугышлар алып баруларын дәвам иттерәләр.

Аеруча көчле сугышлар Сански Мост—Ключ районында (Баня-Лукадан көнбатыштарак) бара. Анда дошман бик күп гаскәрләр һәм сугыш техникасы китергән. Дошман зур югалтуларга дучар ителә. Бихач, Петровац, Коренңца һәм Бугойно пунктлары районыда (Баня-Лукадан көньяк-көнбатыштарак) партизаннар дошманның барлык атакаларын уңышлы рәвештә кире кайтаралар һәм аның техникасын юк итәләр. Вропол якынында партизаннар немецларның 4 танкысын шартлатканнар һәм берничә дистә солдат һәм офицерларны кырып ташлаганнар. Моннан берничә көн элек дошман Петровацны яңадан бомбага тоткан.

Баня-Лукадан көньяк-көнбатыштарак, Плитвичко-Озеро районында немецларның һәм усташаларның һөҗүм итеп килүче отрядлары итальяннар белән кушылганнар һәм партизаннарны бераз кысрыклаганнар. Грачац якынында аеруча каты сугышлар булган. Бу сугышларда немецларның 800 дән артык һәм итальяннарның 1.000 ләп солдат һәм офицерлары үтерелгән һәм яраланган. Күп көннәр дәвам иткән сугышлардан соң партизаннар Сараеводан 60 миль көнбатыштарак Горни-Вакуф шәһәрен оккупантлардан азат иткәннәр.

Бер группа шартлатучы партизаннар Любляна—Загреб линиясендә Требине белән Севница арасындагы тимер юлны сүткәннәр һәм 5 тимер юл станциясен шартлатканнар. Разведчик партизаннар группасы Люблянадан көньяк-көнчыгыштарак Жужемберк шәһәрендә дошман гарнизонына уңышлы һөҗүм ясаган. Партизаннар, берничә дистә солдат һәм офицерларны үтереп, 2 станоклы пулемет һәм башка кораллар кулга төшергәннән соң, үз базаларына исән-сау кайтканнар.

АНГЛИЯ АВИАЦИЯСЕНЕҢ ТУРИНГА ҺӨҖҮМНӘРЕНЕҢ НӘТИҖӘСЕ

ЛОНДОН, 12 февраль. (ТАСС). Экономик сугыш министрлыгының белдерүенчә, Англия авиациясенең Туринга 6 тапкыр ясаган һөҗүмнәре нәтиҗәсендә 70 промышленность предприятиесе зарарланган, шулай ук 65 акр мәйданда шактый җимерелүләр булган.

Италиядә эшләнә торган барлык йөк автомобильләренең 8 дән бер өлешен бирүче «Ланчиа» заводлары җимерелгән. Италиядә эшләнеп чыга торган барлык самолетларның алтыдан бер өлешен эшләүче «Фиат» авиация заводы, пропеллер заводы, ике корыч кою заводы, шулай ук «Фиат»ның броня плиталары өчен авыр корыч коелмалар эшли торган ярдәмче заводы бик нык зарарланганнар. Соңгысының аеруча әһәмиятле булган кайбер цехлары җимерелгән. Англия авиациясенең һөҗүмнәре нәтиҗәсендә Турин халкыннан йөз меңнәрчә кешеләр күчерелгәннәр.

НЕМЕЦ САМОЛЕТЛАРЫНЫҢ ШВЕЦИЯ ЧИГЕН ҮТЕП ЧЫГУЛАРЫ

Швеция артиллериясе немецларның бер самолетын җиргә төшәргә мәҗбүр иткән

СТОКҺОЛЬМ, 12 февраль. (ТАСС). Стокһольм радиосының хәбәр итүенә караганда, Швециянең оборона министрлыгы түбәндәгеләрне белдергән:—11 нче февральдә, көннең икенче яртысында, көньяк Швециядә Сконе провинциясе өстендә Германиянең бер гидропланы күренде. Ул Швециянең диңгез базасы Карлскруна өстеннән очып үткән чакта, зенит артиллериясе аңа каршы кисәтү уты ачты. Самолет кире китмәгәнлектән аңа каршы көчле атыш башланды һәм самолет суга төшәргә мәҗбүр булды. Самолетны һәм аның экипажын хәрби властьлар тотып калдылар.

Шул ук вакытлардарак Сконе районында немецларның икенче самолеты күренде. Берничә тапкыр кисәтү атышы ясалганнан соң ул көньяк-көнчыгышка таба очып китте.

Хәрби хезмәткәрләрнең семьяләренә ярдәм

Шәһәрнең Молотов районында Кызыл Армия һәм Хәрби Диңгез Флоты сугышчыларының һәм командирларының семьяләренә ярдәм күрсәтү буенча киң эш алып барыла. Боларга ярдәм күрсәтүне тагын да яхшырту өчен махсус комиссия төзелде.

1942 нче елда сугышчыларның семьяләренә 4 миллион 583 мең сум дәүләт пособиясе һәм ярдәм бирелгән иде. Соңгы вакытта яңадан 21.830 сум ярдәм бирелде. Соңгы берничә атна эчендә сугышчыларның һәм командирларның семьяләренә 1131 кубометр утын китерелде. 14 оешма буенча гына да хәрби хезмәткәрләрнең семьяләренә 1780 данә төрле кием, 432 пар аяк киемнәре һәм башка әйберләр бирелде. Узган елның көзеннән алып 10 нчы февральгә кадәр аларга 70.000 килограммга якын бәрәңге, яшелчә һәм башка азык продуктлары өләшелде.

Молотов районында хәрби хезмәткәрләрнең семьяләреннән 1000 кеше ашханәләргә беркетелде. Аларга 900 кубометр утын җибәрелде, балаларына 1500 килограмм манный ярма бирелде. Соңгы декада эчендә генә дә хәрби хезмәткәрләрнең балаларына һәм хатыннарына 255 данә күн аяк киеме, 1500 данә төрле кием, 24 пар киез итек, балаларга 1450 пакет төрле бүләкләр бирелде.

Җаваплы редактор И. ҮЗБЕКОВ.

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры янында

ДРАМА ТЕАТРЫ СТУДИЯСЕ АЧЫЛА.

Студиядә Татар дәүләт академия театры өчен квалификацияле артистлар әзерләнәчәк. Студиягә 8—9 класс күләмендә белемнәре булган 16—30 яшьлек кешеләр кабул ителә. Гариза белән бергә яшь турында, белем турында, хәрби хәл турында таныклык бирергә. Гаризалар 15 нче февральгә кадәр кабул ителә. Сынаулар 15 нче февральдән 20 нче февральгә кадәр алып барылачак. Укучыларга айга 130 сум күләмендә стипендия бирелә һәм алар театр янындагы ашханәгә беркетеләләр. Гаризалар 10 сәгатьтән 14 сәгатькә кадәр кабул ителә. Адрес: Казан, Зур Галактионов урамы, 13 нче йорт.

46-1-1

Шушы елның 15 нче февралендә 1942 нче елгы

ДӘҮЛӘТ ХӘРБИ ЗАЕМЫ БУЕНЧА РАСЧЕТ ЯСАУ

срогы тәмам булу уңае белән Татарстан АССР ның хезмәт саклык кассалары һәм дәүләт кредиты идарәсе белдерә:

Предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның баш (өлкән) бухгалтерлары подписка буенча үзләренә тиешле барлык облигацияләрне саклык кассаларыннан алырга, февральнең икенче яртысы өчен хезмәт хакы түләгән вакытта аларны һәрбер подписчикка тапшырырга һәм подписканың йомгаклары, шулай ук облигацияләрне тапшыру турында шушы елның 1 нче мартына саклык кассаларына отчет бирергә тиешләр.

Район финанс бүлекләренең налог агентларына подписка буенча колхозчыларга облигацияләрне тапшыруны тикшерергә һәм аларны тәмам тапшырып бетерүне тәэмин итәргә, подписканың йомгаклары һәм облигацияләрне тапшыру турында шушы елның 1 нче мартына район саклык кассаларына отчет җибәрергә тәкъдим ителә.

Комсодлар заем буенча расчетларның һәм подписчикларга облигацияләр тапшыруның үз вакытында тәгәлләнүен тикшереп торырга тиешләр.

Татарстан АССР ның хезмәт саклык кассалары идарәсе.

53 1-1

Театрларда һәм киноларда

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры. Бүген көндезгә спектакль булмый. Алынган билетлар белән 21 нче февральдә керергә ярый. Кич—„*Хуҗа Насретдин*“.

Зур драма театры. Бүген көндез һәм кич—„*Фронт*“.

Дәүләт циркы. Бүген—зур цирк тамашасы һәм французча көрәш ярышлары. Кич 8 сәгатьтә башлана.

„Электро“ — музыкаль комедия „*Антоша Рыбкин*“.

„Унион“—„*Котовский*“

„Пионер“—көндез һәм кич — „*Корыч ничек чыныкты*“.

„Чаткы“—„*Өч мушкетер*“.

„Кызыл йолдыз“—„*Райком секретаре*“.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор, редактор урынбасары— АТС 76—29, секретарь, промышленность - транспорт һәм авыл хуҗалыгы бүлеге— АТС 79—29. типография 36—60.

ПФ645 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 263